Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре җаваплары
2017-2018 уку елы
9 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 90 минут.
Максималь балл – 54.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Н.Хәсәнов иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан тел арты (кече тел) ассимиляциясе чагылыш тапкан сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) *Бүген ай сурәте тәңкәләнеп аккан Нократ суы өсләрендә дә үтә сафланып ялтырый.*

ә) *Өй эчләре тәмле-тәмле татар ризыгы исләре белән тулган.*

б) *Көтеп алынган Сабан туе үзен кайда да сиздерә.*

в) *Инде халык төрле урамнан яшел болынның түгәрәк мәйданына ашыкты.*

2. *Ямь-яшел* сүзендә **ь** хәрефе ни өчен язылуы дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) аеру билгесен белдерү өчен

ә) иҗекне нечкәртү өчен

б) алынма сүз икәнен белү өчен

в) һәмзә тартыгын белдерү өчен

3. **Инглиз алынмаларыннан гына торган рәтне билгеләгез.** ***(2 балл)***

а) фильм, клоун, бокс, парк

ә) алфавит, музей, химия, вирус

б) комбайн, пенал, циркуль, ручка

в) фонтан, газета, макарон, концерт

4. Бирелгән мисалдагы омонимнарның төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

Кара әле, дустым, кара,

Кара карга очып бара. (Ә.Бикчәнтәева)

а) саф лексик

ә) омограф

б) омоформа

в) омофон

5. ***Алтынчыларының*** сүзенең мәгънәле кисәкләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) алты-н-чы-лар-ы-ның

ә) ал-тын-чы-лар-ы-ның;

б) алты-нчы-лар-ының

в) алты-нчы-лар-ы-ның

6. Җөмләдәге аваз ияртеменең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Ишегалдындагы табага туралган ипине сала башлауга, “пип-пип” диешеп, бәбкәләр килә. (Ф.Яруллин)

а) ялгызак

ә) парлы

б) кабатланып килгән

в) ике компонентлы

7. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Ана керпе белән ата керпе парлашып **ауга** киттеләр.* (К.Кәримов)

а) хәбәр составына керә

ә) максат хәле

б) кыек тәмамлык

в) сәбәп хәле

8. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Алар түккән күз яше шулкадәр күп иде: бу яшь ташкыны, чишмә булып, җир астыннан өскә бәреп чыгар сыман иде. (Г.Гыйльманов)

а) аналитик иярченле кушма җөмлә

ә) синтетик иярченле кушма җөмлә

б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

в) катнаш кушма җөмлә

II. Теоретик бирем.

Автобиографиягезне языгыз. ***(10 балл)***

III. Гамәли һәм иҗади бирем.

Эшчәнлек – белемгә бердәнбер юл. (Бернард Шоу)

1. *Юл* сүзенә фонетик анализ ясагыз. ***(2 балл)***

2. Һәр сүзнең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. ***(8 балл)***

3. *Бердәнбер* сүзенә морфологик анализ ясагыз. ***(3 балл)***

3. Җөмләгә тулы синтаксик анализ ясагыз. ***(5 балл)***

4. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***